ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 31 маенда
кабул ителде

## 1 статья. Әлеге Законның хокукый җайга салу предметы

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында театрлар эшчәнлеге мәсьәләләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре чикләрендә җайга салуны күз алдында тота.

2. Театрлар һәм театр эше турындагы Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының тиешле нигезләмәләренә таяна һәм әлеге Законнан һәм аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларыннан гыйбарәт.

## 2 статья. Татарстан Республикасының театр эше өлкәсендәге дәүләт сәясәте

Татарстан Республикасының театр эше өлкәсендәге дәүләт сәясәте түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1) театр сәнгатен үстерү өчен шартлар тудыруны, татар, рус драматургиясен һәм башка халыклар драматургиясен саклап калуны һәм үстерүне;

2) аерым категориядәге гражданнар өчен театр сәнгатеннән файдалану мөмкинлекләрен киңәйтүне, театрларның тамашачылар аудиториясен арттыруны;

3) Татарстан Республикасында театрларга ярдәм итүне, аларның матди-техник базасын, театрларның мөстәкыйль оешу механизмнарын камилләштерүне;

4) театр эшчәнлеген заманча таләпләргә туры килә торган кадрлар белән тәэмин итүне.

## 3 статья. Театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре

1. Театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасында театр эшен оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

3) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Театр эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) театр эшен җайга салу мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар чыгару;

2) Татарстан Республикасында театр сәнгатенә ярдәм итүнең һәм аны үстерүнең дәүләт программаларын раслау;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт театрларын булдыру, үзгәртү һәм ябу турында карарлар кабул итү;

4) Татарстан Республикасында театрлар эшчәнлеге өчен икътисадый һәм аны оештыру шартлары тудыру;

5) аерым категориядәге гражданнар өчен Татарстан Республикасы дәүләт театрларына йөрүгә ташламалар билгеләү тәртибен раслау;

6) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт театрларын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт театрларын булдыру, үзгәртү һәм ябу турында тәкъдимнәр әзерләү;

3) Татарстан Республикасында театрлар реестрын алып бару;

4) инвалидларга федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт театрларына йөри алу шартларын тәэмин итү;

5) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

4 статья. **Театр эше өлкәсендә дәүләт ярдәме**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасында театрларга дәүләт ярдәме күрсәтәләр, шул исәптән түбәндәгеләр аркылы:

1) Татарстан Республикасында театрларны саклап калу, торгызу һәм үстерү максатларында инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү;

2) Татарстан Республикасында театрлар эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүгә булышлык күрсәтү;

3) оештыру-хокукый рәвешләре нинди булуга карамастан, театрлар иҗат коллективларының (труппаларының) республика, төбәкара, гомумроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге мәдәни чараларда катнашуына ярдәм итү;

4) театрларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

5) квалификацияле белгечләр укытуга һәм әзерләүгә булышлык күрсәтү;

6) яңа театраль постановкалар иҗат итүгә булышу;

7) Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә торган башка чаралар.

5 статья. **Татарстан Республикасында театрлар реестры**

1. Татарстан Республикасы территориясендә, милек рәвешләренең нинди булуына карап, түбәндәге театрлар эшли һәм төзелә ала:

1) дәүләт;

2) муниципаль;

3) хосусый.

2. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән театрларны исәпкә алу максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасында театрлар реестры (алга таба – реестр) алып барыла. Реестр белешмәләре Татарстан Республикасында театр сәнгатенә ярдәм итүнең һәм аны үстерүнең дәүләт программаларын әзерләгәндә файдаланыла.

3. Реестрга белешмәләр кертү һәм аны алып бару Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасында театрлар реестры турындагы нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла.

6 статья. **Театрлар эшчәнлегенең максатлары һәм төрләре**

1. Театрлар эшчәнлегенең максатлары театр сәнгатен үстерүдән, тамашачыларның сәхнә сәнгатенә булган рухи ихтыяҗын барлыкка китерүдән һәм канәгатьләндерүдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасы дәүләт театрлары учреждениеләр рәвешендә төзеләләр һәм керем китерә торган эшчәнлекне бары тик театрлар эшчәнлегенең әлеге статьяның 1 өлешендә каралган максатларына ирешү өчен хезмәт иткән очракта гына башкара алалар.

3. Театрлар эшчәнлегенең төп төрләре түбәндәгеләр:

1) спектакльләр, театраль тамашалар иҗат итү һәм күрсәтү, гастрольләр, концертлар оештыру, иҗат кичәләре, фестивальләр һәм конкурслар үткәрү, күрсәтелгән чараларга билетлар сату;

2) авторларның һәм рольләрне (партияләрне) башкаручыларның хокуклары Россия Федерациясе законнары нигезендә сакланган хәлдә, юридик һәм (яисә) физик затларның үз мәйданнарында яисә алар тарафыннан арендага алынган сәхнә мәйданнарында күрсәтү өчен, телевидениедән күрсәтү өчен, радиодан тапшыру өчен, интернет-трансляция өчен, кинога, фотога, видеога һәм башка матди

саклагычларга төшерү өчен юридик һәм (яисә) физик затлар белән шартнамәләр нигезендә театраль постановкалар, концертлар әзерләү;

3) профессиональ иҗат хезмәткәрләренә театрның әйдәп баручы осталары һәм эшлекләләре тарафыннан стажировкалар үткәрү;

4) спектакльләр күрсәтү, концертлар, тамашалар үткәрү өчен оешмаларга шартнамәләр нигезендә сәхнәгә кую хезмәтләре күрсәтү, сәхнәгә кую чараларын бирү;

5) юридик һәм (яисә) физик затларның заказлары буенча театраль постановкаларның, концертларның, тамашаларның сәнгати бизәлеше предметларын ясау;

6) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз сәхнә мәйданнарын гастрольләр һәм күчмә чаралар, уртак театраль проектлар һәм программалар уздыру өчен башка театрларга биреп тору;

7) авторларның һәм рольләрне (партияләрне) башкаручыларның хокуклары Россия Федерациясе законнары нигезендә сакланган хәлдә театр эшчәнлегенә бәйле мәгълүмат-белешмә һәм реклама материаллары, киноматериаллар, фотоматериаллар, видеоматериаллар һәм фонограммалар әзерләү, аларны күбәйтү һәм реализацияләү;

8) костюмнарны, аяк киемнәрен, җайланмаларны, реквизитны, бутафорияне, грим әйберләрен һәм башка әйберләрне прокатка бирү һәм сату;

9) тамашачыларга өстәмә хезмәтләр күрсәтү;

10) театр тарихына һәм эшчәнлегенә бәйле экспозицияләр төзү һәм күрсәтү.

7 статья. **Театрларның хокуклары һәм бурычлары**

1. Россия Федерациясе законнары нигезендә театрлар түбәндәгеләрне мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырырга хокуклы:

1) репертуарны һәм үз эшчәнлегенең сәнгати юнәлешен сайларга;

2) үзенең иҗади һәм хуҗалык ресурсларыннан, иҗади һәм социаль үсеш зарурлыгыннан чыгып, үз эшчәнлеген планлаштырырга һәм үсеш перспективаларын билгеләргә;

3) түләүле хезмәт күрсәтүләргә һәм театр тарафыннан сатыла торган продукциягә бәяләр билгеләргә;

4) театрның эш режимын һәм эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләргә;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

2. Театрлар гамәлгә кую документларында тасвирланырга тиешле үз символикасын – эмблемалар, герблар, башка геральдика билгеләре, флаглар һәм гимннар булдырырга хокуклы. Театрларның символикасы Россия Федерациясе законнарында коммерциягә карамаган оешмаларның символикасына карата куела торган таләпләргә туры килергә тиеш.

3. Татарстан Республикасында театраль тамашаларны гавами башкару һәм (яисә) гавами күрсәтү белән шөгыльләнүче театрлар түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) театраль тамаша вакытында тамашачыларның гомерен һәм сәламәтлеген, шулай ук аларның саклауга тапшырылган мөлкәтен саклауны тәэмин итүне;

2) билетлар сату урыннарында һәм театраль тамашаны гавами башкару һәм (яисә) гавами күрсәтү урыннарында, һәркем күрерлек итеп, тамаша нигезләнгән әсәрнең тулы исеме, авторы, куючыларның һәм төп рольләрне (партияләрне) башкаручыларның исемнәре, шулай ук театр ихтыяры буенча башка белешмәләр күрсәтелгән афиша урнаштыруны;

3) театраль тамашаның үткәрелү урыны, башлану һәм тәмамлану вакыты турында, билет бәяләре, аларны сатып алу һәм кире тапшыру шартлары хакында, аерым категориядәге тамашачылар өчен каралган ташламалар, театраль тамашага керү өчен яшь ягыннан билгеләнгән чикләүләр турында тамашачыларга мәгълүмат бирүне;

4) театр билетында хезмәт күрсәтүләрнең бәясен, театрның исемен, аның оештыру-хокукый рәвешен, театраль тамашаның исемен, күрсәтелү урынын, датасын һәм вакытын, тамаша залындагы урынны күрсәтүне.

4. Афишалар, башка күрсәтмә мәгълүмат текстлары Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә языла.

5. Гражданнарга мәгълүмат бирү максатларында театр кассалары янында театраль тамашаларга һәм спектакльләргә билетлар булу-булмау турында актуаль мәгълүмат урнаштырыла.

6. Театрлар биналарында инвалидларга хезмәт күрсәтүләрдән файдалану шартлары федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә тәэмин ителә.

7. Театрлар театраль тамашаларны субтитрлар ярдәмендә яисә синхрон тәрҗемә аша Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, шулай ук башка телләрдә аңлатуны тәэмин итә ала. Күрсәтелә торган хезмәтләр турындагы мәгълүмат гражданнар билет сатып алганчы, театр администрациясе билгеләгән тәртиптә хәбәр ителергә тиеш.

8 статья. **Театрларга йөргәндә ташламалар**

1. Түләүле чаралар оештырганда театрлар мәктәпкәчә яшьтәге балалар, белем алучылар, инвалидлар, чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, башка категориядәге гражданнар өчен ташламалар билгеләргә мөмкин.

2. Татарстан Республикасы дәүләт театрларына йөргәндә аерым категориядәге гражданнар өчен ташламалар билгеләү тәртибе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, муниципаль театрлар өчен җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә. Башка театрлар тамашачыларга түләүле чаралар өчен ташламаларны мөстәкыйль билгеләргә хокуклы.

9 статья. **Дәүләт театрлары һәм муниципаль театрлар эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү**

Татарстан Республикасында дәүләт театрлары һәм муниципаль театрлар эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән, шулай ук федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль хокукый актлар белән тыелмаган бюджеттан тыш чыганаклардан башкарыла.

10 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт театрларының профессиональ иҗат хезмәткәрләрен аттестацияләү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт театрларының профессиональ иҗат хезмәткәрләренә театрның сәнгать персоналы һәм театрның иҗат составы (труппа) керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт театрларында театрлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, театраль постановкаларны сыйфатлы әзерләүне тәэмин итү, кадрларны рациональ сайлап алу максатларында профессиональ иҗат хезмәткәрләренә аттестация үткәрелә, аның барышында әлеге хезмәткәрләрнең осталык дәрәҗәсе, профессиональ сыйфатлары, Татарстан Республикасы дәүләт театры эшенең перспектив һәм агымдагы планнары нигезендә киләчәктә эшләү мөмкинлеге бәяләнә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт театрларының профессиональ иҗат хезмәткәрләренә аттестация аттестацияләү турында театрда расланган нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм даимилектә уздырыла. Иҗат хезмәткәрләрен аттестацияләү турында типлаштырылган нигезләмә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәният өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 11 июне
№ 43-ТРЗ